РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Буа шәһәре

14.03.2024 № 66 Бк/к

Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы
белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган
гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенә
үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2023 елның 10 июлендәге 293-ФЗ номерлы Федераль закон, РФ Хөкүмәтенең 2023 елның 29 декабрендәге 2386 номерлы «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасы турында» карары нигезендә ТР Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. ТР Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 9 сентябрендәге 404-п номерлы ( 23.01.2014 №10-п, 26.03.2014 №125-п, о22.10.2015 №533-п, 27.10.2015 №538-п, 05.05.2016 №189-п, 06.03.2017 №88-п, 11.01.2018 №3-п, 22.08.2019 №357/ик-п, 07.03.2021 №54/Бк/к, 25.05.2021 №136/Бк/к карарлары редакциясендә) карары белән расланган Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенә (алга таба- Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 3нче бүлегендәге 3.11 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.11. Әлеге тәртипкә ярашлы рәвештә социаль ярдәм чаралары күрсәтүче органнар күрсәтелгән социаль ярдәм чараларын социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформада (алга таба – ЕЦП) Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә һәм еп ЕЦП операторы билгеләгән форматларга туры китереп урнаштыруны тәэмин итә.

Әлеге Тәртиптә күрсәтелгән гражданнарга социаль ярдәм чаралары турында мәгълүмат Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә ЕЦП

куллану һәм ЕЦП операторы билгеләгән форматларга ярашлы рәвештә алынырга мөмкин.»

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми http://pravo.tatarstan.ru/ порталында , рәсми рәвештә басылып чыккан көннән башлап законлы көченә керә, шулай ук Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында http://buinsk.tatarstan.ru Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылырга тиеш.

3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны ТР Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Л. Н.Садретдиновага йөкләргә.

Җитәкче Л.Р. Шакирҗанов